وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклапябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№13 (130). 30 март 2012 / 8-җөмәдел-әүвәл-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ





Диннәр тарихын укыту үзенчәлекләре ▷2◁



Күп хатынлылык ▷2◁



Ш.МӘРҖАНИ образы әдәбиятта һәм сәнгатьтә ▷3◁


## ЯҢАЛЫКЛАР

**БОЛГАРДА ЭШ КАЙНЫЙ**

Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз, ТР Президентының Дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы Марат Гатин, Спас муниципаль районы башлыгы Камил Нугаев һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәте хезмәткәрләре Болгарда алып барыла торган төзелеш эшләре белән танышты. Әлеге сәфәр Идел буе Болгарстаны тарафыннан ислам дине кабул ителү көненә (21 май) багышланган тантаналы чараларга әзерләнү һәм Казанның Кол Шәриф мәчетендәге иң зур басма Коръәнне Болгарга күчерү мәсьәләләрен хәл итү белән бәйле иде.

Кунаклар шулай ук "Саклаучы (Хранительница)" сыны урнаштырылырга мөмкин булган урынны да карады.

**ТУКАЙ РАЙОНЫНДА – ЯРЫШ**

Тукай районындагы Яңа посёлок мәчетендә пәйгамбәрләр тарихына багышланган ярыш узды.

16 яшькәчә балалар пәйгамбәрләр тарихы буенча белемнәрен барлады. Ярыш ике турда үтте. I турда балалар компьютер белән эшләү осталыкларын күрсәтте. II турда һәр катнашучыга бишәр сорау бирелеп, пәйгамбәрләр турындагы белемнәре тикшерелде, - дип яза www.tatar-inform.ru сайты.

Мөгаллимәләрдән торган жюри әгъзалары җиңүчеләрне билгеләде. Калмаш мәхәлләсеннән Гадел Рәкыйпов, Теләнче Тамак мәхәлләсеннән Рәүф Мөхәммәдиев, Яңа Сарайлы мәхәлләсеннән Булат Гыйльфанов, призлы урыннар яулап, белемнәренең югары булуын раслады, дип хәбәр итте ярышны оештырган Тукай районы мөхтәсибе Җәүдәт хәзрәт Харрас.

**ТЕЛӘЧЕДӘ ОЧРАШУ УЗДЫ**

Теләче районы мәдәният йортында Балтач районының Мөслимәләр берлеге җитәкчесе, табибә Рәйсә ханым Зарипова белән "Ислам һәм сәламәтлек" темасына очрашу үткәрелде. Очрашуга ислам дине белән кызыксынучы хатын-кызлар килде.

Теләченең Ихлас мәчетендә район җитәкчелеге һәм җирле эшмәкәрләр ярдәме белән районкүләм Коръән бәйгесе дә үткәрелде. Биредә илледән артык бала катнашты. Балалардан Коръәнне аһәңле итеп уку, тәҗвид кагыйдәләрен белү, намаз уку тәртибен сөйләп күрсәтү соралды.

**БӨГЕЛМӘДӘ – ЯЗГЫ БАЛАЛАР ЛАГЕРЕ**

Бөгелмә шәһәренең Җәмигъ мәчетендә 30 мартка кадәр малайлар һәм кызлар өчен балалар лагере эшләде.

Балалар лагерьда ислам дине нигезләрен һәм әдәп-әхлак кагыйдәләрен өйрәнде. Башка еллардан аермалы буларак, бу лагерь балаларның сәламәтлеген рухи яктан гына түгел, физик яктан да ныгытуны максат итеп куйган иде.

*Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

# Кешеләргә дин кирәк

**Соңгы вакытта күп кенә кеше "Ходайга ышану ни өчен кирәк?" дигән сорауга җавап эзли. Без бу сорауны телевизор экраннары аша да ишетәбез, аны блог һәм мәкаләләргә дә кертеп җибәрәләр, дуслар һәм таныш-белешләр дә әледән-әле бу теманы читләтеп үтми. Моның сәбәбе - Аллаһы Тәгаләгә ышануның нәрсә икәнлеген дөрес аңламауда. Бүген дөньяда күбрәк матди якка игътибар бирәләр, рухи як игътибар үзәгеннән читтәрәк кала. Шулай да, кешегә дин нәрсә өчен кирәк соң?**



Һәр кеше бәхетле булырга тели. Бәхет - иң элек үз-үзең белән гармониядә булу. Бу исә кеше үзенең дөньяда тоткан урынын, үтәргә тиешле эшләрен, яшәвенең максатын төгәл белгәндә генә мөмкин. Башкача булганда, яшәешнең максаты югала. Иман һәм шәригать кануннары кешенең дөньяда яшәвенең максатын - камиллекнең иң югары дәрәҗәсенә ирешүне билгели.

Дөньяда бай, яшь, сәламәт, матур була торып та, үзләрен бик бәхетсез итеп хис иткән кешеләр байтак. Матур да, бай да, сәламәт тә була торып, тормышларыннан канәгать булмаган кешеләр дә очрый. Күпчелек очракта, бу - рухи нигез булмау аркасында. Дин - үзеңнең житешсезлекләреңне күрә белергә ярдәм итә. Бу илаһи система аша гына кешене тәрбияләү һәм камилләштерү буенча эш алып барыла. Диннең төп максаты - җәмгыятебездә югары әхлаклы кешеләр тәрбияләү. Мондый кешеләр белән ил дә алга китәчәк һәм чәчәк атачак. Дин кешене төрле яманлыклар кылудан саклый. Саклап кына калмый, начар ниятләрнең асылын, сәбәп һәм нәтиҗәсен дә аңлата. Дин, мисал өчен, суицидлыкка (үз-үзеңне үтерүгә) каршы көчле чара булып тора. Сербский исемендәге Социаль һәм суд психиатриясе фәнни үзәге соңгы 20 ел эчендә Россиядә үз-үзеңә кул салу очракларын тикшергән. Алынган мәгълүматлар буенча, 1990 елдан 2010 елга кадәр 800 мең россияле үз-үзенә кул салган. Соңгы вакытта Россия суицидлык очраклары буенча алдынгы урыннарның берсен били. Ел саен илебездә 2800 бала үз-үзенә кул сала. Бу санның азмы-күпме икәнлеген аңлар өчен, мондый чагыштыру китерергә мөмкин: 2001 елда үз-үзенә кул салудан үлүчеләр саны сугыш һәм криминаллар аркасында үлгән кешеләр санын узып киткән. Үз-үзенә кул салучыларның иң күбесе Көнчыгыш Европа илләрендә күзәтелсә, иң азы - мөселман дәүләтләрендә. Суицидлык сәбәпләре төрле булырга мөмкин, ләкин аның төп асылы бер әйбердә - динсезлектә һәм киләчәккә өмет булмауда.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# БОЛГАР ӨЧЕН "ЧУДОВИЩЕ"

**Соңгы вакытта татар-мөселман дөньясында актив фикер алышу, бәхәсләр Даши Намдаковның "Саклаучы (Хранительница)" дип аталган сыны тирәсендә куера. Һичшиксез, сынның авторы - талантлы скульптор. Аның эше гаҗәп-хәйран калырлык, гаять тә үзенчәлекле. Мөгаен, мин Д.Намдаковны чорыбыз даһие дип атасам да, ялгышмамдыр. Ә ни өчен соң, алайса, бар мөселман җәмәгатьчелеге, сирәк була торган бердәмлек күрсәтеп, Болгарда Намдаковның 12 метрлы "Саклаучы" сынын урнаштыруга каршы рәхимсез чыгыш ясый? Әйдәгез, әлеге сорауга җавап табып карыйк.**

Татарлар өчен Болгар - ул үзгә, сакраль урын. Бу татар халкын үзенә тартып торган үзәк. Безнең үзаңыбыз өчен Болгарның тел белән аңлатып бетергесез әһәмиятен билгеләү бик тә катлаулы. Ул шул хәтле тирән ки, ел саен унарлаган мең татар кешесе илебезнең төрле почмакларыннан бирегә бөек Җыенга кайта. Халкыбызның милли тормышында бу кадәр санда татар халкы омтылган бүтән бернинди чара юк. Бернинди дә!

Мин мөселманнар Диния нәзарәте институтының сакраль әһәмияте турында яздым инде, ул татар өчен халкыбызны бер төшкә беркетеп торучы милли дәүләтчелек, рухи хәлифәт фикере белән калыплашкан. Мөселманнарның Диния нәзарәте институты - ул безнең рухи "Ясриб"ебез, аның әйләнәсенә татар өммәте җыела. Гасырлар дәвамында Россиянең төрле өлкә һәм шәһәрләре буйлап таралган татар милләтеябышып торган каркас бу. Болгар үзенә сеңгән мәгънәсе буенча татар халкы аңында шул ук тирән, тектоник катламнар белән бәйле. Болгар - ул милли дәүләтчелек символы. Бу аның турында хәтер. Бу - безнең өчен рухи бозлы яңгырга тиң, бары тик ташка чокып язылган гына: ягъни, шул ук "Ясриб"ебез инде ул. Шунысын да искә алыгыз: хәтта традицион татар шәмаилләрендә дә Коръән аятьләре Мәккә, Мәдинә фонында гына түгел, шул ук борынгы Болгар фонында да язылалар. Бу юкка гына түгел. Һәм бу символлар белән уйнарга ярамый.

Татарның Мәскәүдәге Җәмигъ мәчетен җимерүгә китергән реставрациягә карата көчле реакция дә, һәм аннан калышмаган шау-шуларның берсе булган - Болгарда пәйда булачак Намдаков ясаган 12 метрлы могҗиза барлыкка килү мөмкинлегенә карата килеп чыккан көчле реакция дә - татар халкының коллектив җанындагы иң нечкә кыллар тетрәнү сәбәпләреннән булды. Мәчет сүтелү очрагында исә татар милләтенең тәнендәге бик тә әһәмиятле сөяк чатнады. Мәчет зураер, икенче бер төскә керер кебек иде. Ни өчен халык бик нык ачулы соң? Аны таяну нокталарының берсеннән вакытлыча азат иткәннәре өчен. Әмма тәнеңдәге үз сөягең "иске" булуга да карамастан, аны нинди дә булса яңасына алмаштыру - ул гел авырыксындыра торган операция. Шуңа бәйле рәвештә шундый ризасызлык дулкыны барлыкка килде дә.

Татарлар Намдаковның иҗат җимеше мисалында, нинди дә булса бер чит кеше шакшы аяк киемнәреннән өй түренә үтеп, аның кагылгысызлыгын пычраткан төсле хис итә. Теләсә кайсы татар кешесеннән сорагыз: алар Болгардагы Җәмигъ мәчет хәрабәләре белән янәшәдә торган чиркәүгә ничек карыйлар икән? Һәм алар сезгә бернинди тоткарлыксыз: "Бу - иң кадерле әйберебезнең йөрәгендә коточкыч яра эзе", - дип әйтәчәк. Беркем дә аны сүтү-җимерү турында сүз алып бармаячак (сәяси нәзакәтлелек, үзара ихтирам, диалог), әмма монда безнең барыбызның да тәненә нindидер чит-ят әйбер кадалгандай булуны һәр кеше дә сизә. "Саклаучы (Хранительница)" сыны белән дә шулай ук.

Бөтен хикмәт тә шунда ки, Намдаков - будда динен тотучы. Будда дине аның талантлы иҗатында киң чагылыш тапкан.



*(Ахыры 2 нче биттә.)*

# БОЛГАР ӨЧЕН "ЧУДОВИЩЕ"

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Аның хезмәтләрендә будда дине нинди роль уйнавы турындагы сорауга, ул, аңа, будда динен тотучы буларак: "Минем өчен мондый сорауны ишетү хәтта сәер", - дип җавап бирде. Кемдер әйтергә мөмкин: "Рәссамның кайсы конфессиягә каравы мөһим түгел, иң мөһиме - аның иҗаты нинди идея һәм символлар трансляцияләүдә". Әлбәттә, шулаен шулайдыр да, әмма бу очракта түгел. Намдаков үзенең "Саклаучы (Хранительница)" сынын, болгар символизмына берничек тә яраштырмыйча, 2003 елны ук ясаган. Аның күзаллавында символик фикерләр бөтенләй юк бит! Аның хезмәте Болгар өчен дә, безнең өчен дә түгел!!! Бары тик 2011 елның җәендә, Казан Кремле әлеге бурят рәссамы күргәзмәсен кабул иткәндә генә, Канатлы барс һәм "Саклаучы (Хранительница)" сыннарының берникадәр охшашлыгы күреп алынды (ул татарның Канатлы барсы белән янәшә "Хәзинә" сәнгать галереясына керү юлындагы газонда торган иде). Шунда аны, бары зурайтып кына, Болгарга урнаштыру идеясе туды да инде. Күпләр әлеге фактларны белми. Әмма барысы да бердәм рәвештә әлеге сында кай төшедер көтелгәнчә түгел дип хис итә. Ул ничектер чит, үз түгел кебек. Скульптура традициясе үзе үк төп нигезе буенча мәҗүсилектән һәм ул сакраль Болгарның ислам символикасына берничек тә берекми.

Әмма шәхсән миңа "Саклаучы"-ның Канатлы барс белән охшашлыгы уйланылган кебек тоела, ә аны Болгарга урнаштыру перспективасы миндә чирканудан башка берни дә уятмый. Һәм минем кебекләр зур күпчелекне тәшкил итә. Болгарны тынычлыкта калдырыгыз! Һәм "модный" скульпторларның мәһабәт монументларыннан башка да халкыбыз әлеге урынны хөрмәт итәчәк.

***Рөстәм хәзрәт БАТЫР,***
***ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең***
***Голәмәләр шурасы рәисе***

# КҮП ХАТЫНЛЫЛЫК

*"Чынлыкта, Аллаһ каршында хак дин - ислам дине" (3:19).*

Шушы хакыйкатьне инкарь иткән совет дәүләте таркалды, халкыбызның динсез чоры узды, тормыш үзгәрде. Бөтен кеше дә дини дип әйтмәсәк тә, дин тоту рөхсәт ителә, теләгән кеше тота ала. Мең елдан артык ислам динендә булып, милләт буларак ислам динендә формалашкан халкыбыз бүген яңадан ислам диненә тартыла. Күпме генә секталар, төрле диннәр үтеп керергә тырышсалар да, халкыбызга ислам дине якынрак. Ул үзен Ислам дөньясының бер кисәге итеп тоя. Шулай булса да, совет чорындагы дингә каршы булган фикерләү, караш кеше күңелендә калды. Диндә булган күп кенә нәрсәләрне ул кабул итеп бетерә алмый. Динебездә рөхсәт ителгән, әмма совет чорында дингә каршы көрәштә төп коралларның берсе итеп кулланылган һәм шул сәбәпледер халкыбызның күпчелеге күңелләре белән кабул итеп бетерә алмый торган шундый нәрсәләрнең берсе - ирләргә 2, 3, яисә 4 хатын белән тору, ягъни күпхатынлылык. Кайберәүләр күпхатынлылыкның интим ягын гына күз алдында тоталар һәм шул сәбәпле күпхатынлылык белән ирләрнең зина кылып йөрүләреннән аерма күрмиләр. Кайберәүләр Көнчыгыш халкына гына хас күренеш дип, киноларда күрсәтелә торган гаремнарны күзаллыйлар. Кайберәүләр фикеренчә, күп хатынлы ир үзенең хатыннарына золымлык кыла. Алай карасаң, бер генә хатын белән торып шул бер хатынына да золымлык кылучы ирләр дә аз түгел. Бүгенге көндә, гомумән алганда, никах мәсьәләсенә игътибар кимү сәбәпле, кайберәүләр аңа хәтта көлеп кенә карыйлар: янәсе 2, 3, 4 түгел, аның берсе дә кирәкми.

Кеше ирле-хатынлы булып нәсел калдыру өчен, үрчү өчен халык кылына. Ул никахлашырга, гаилә корырга тиеш. Бу тормышта һәркемгә тиешле урын, дәрәҗә билгеләнгән. Ир ир итеп, хатын хатын итеп яратылган. Шуңа күрә дә күпхатынлылыкны аңлау өчен иң элек ир белән хатынның яратылу тарихларын, бер-берсенә карата мөнәсәбәтләрен, үз араларында булган өстенлекләрен карап китәргә кирәк. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Тәхкыйк төп атагыз - Адәмне балчыктан халык кылдык, соңра күркәм сүрәтле иттек, моннан соң фәрештәләргә әйттек: "Адәмгә карап сәҗдә кылыгыз" (7:11).

Аллаһы Тәгалә иң элек анабыз Һаваны түгел, бәлки атабыз Адәмне халык кыла, фәрештәләргә атабыз Адәмгә сәҗдә кылырга боера һәм фәрештәләр атабыз Адәмнең өстенлеген танып сәҗдә кылалар. Аллаһы Тәгалә Адәмне гади мәхлук итеп кенә халык кылмый, ул аны хәлифә итеп халык кыла. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Һәм Раббың фәрештәләргә әйтте: "Мин, әлбәттә, җир өстендә хәлифә итеп Адәмне кылачакмын" (2:30).

Хәлифә итеп атабыз Адәм шәхсән үзе генә түгел, бәлки, гомумән алганда, ир-ат билгеләнә. Пәйгамбәребез Мөхәммәт (сгв) әйтә: "Сезнең һәрберегез көтүче һәм һәрберегез үзенең көтүе өчен җаваплы. Имам - көтүче һәм үзенең көтүе өчен җаваплы, ир-ат үзенең гаиләсе өчен көтүче һәм ул үзенең көтүе өчен җаваплы, хатын-кыз үзенең иренең өендә көтүче һәм үзенең көтүе өчен җаваплы, хезмәтче үзенең хуҗасының маллары өчен көтүче һәм ул үзенең көтүе өчен җаваплы, һәм сезнең һәрберегез көтүче һәм үзегезнең көтүегез өчен җаваплы" ("Бохари", 844; "Мөслим", 7408).

Бу хәдистән күренгәнчә, ир-ат - гаиләсенә, ягъни хатынына, балаларына көтүче. Хатын-кыз исә фәкать үзенең иренең өендә көтүче. Кемнең кем өстеннән көтүче икәнен Аллаһы Тәгалә билгеле. Хатынның яисә ирнең теләге белән генә вазифаларны алышу хаклыкка туры килми.

Аллаһы Тәгалә атабыз Адәмне балчыктан халык кыла. Аннан соң гына анабыз Һаваны халык кыла һәм анабыз Һаваны балчыктан түгел, бәлки атабыз Адәмнең кабыргасыннан халык кыла. Шуңа күрә дә бу ике зат: ир-ат һәм хатын-кыз һич кенә дә урыннарын алыштырып куя торган тигез дәрәҗәдәге затлар түгел. Ирләрнең өстенлеге турында Аллаһы Тәгалә әйтә: "Ирләрнең дәрәҗәсе хатыннар дәрәҗәсеннән өстенрәк, Аллаһ барча эштә белеп хөкем итүче" (2:228).

Ә инде нинди сыйфаты белән өстенлеге турында Аллаһы Тәгалә икенче бер аятьтә тулырак итеп аңлатып әйтә: "Ирләр хатынга әдәп, тәрбия бирү өчен җаваплыдыр. Аллаһ мәхлукларны кайберләрен кайберләреннән артык кылу белән, ирләр акылда, куәттә хатыннардан өстен булды һәм малларын хатыннарга бүлеп бирү белән дә ирләрнең дәрәҗәсе өстендер" (4:34).

Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә ачык итеп әйтә: ирләр акылда һәм куәттә хатыннардан өстен. Халыклар, милләтләр куәтле җитәкче булганда гына алга баралар. Гаиләдә дә шулай, гаилә башлыгы көчле, куәтле булып һәр эшен акыл белән башкарганда гына ул гаилә тәртипле, көчле һәм нык гаилә була. Хәтта кыргый хайваннарның көтүләрен дә көчле, күәтле булганнар гына җитәкли. Бу хакыйкатьне ирләр генә түгел, бәлки хатыннар да аңларга тиешләр.

Гаиләләр ныклы булса гына илләр, дәүләтләр ныклы була, халыклар куәтле була. Гаилә төшенчәсе ул бүгенге көндәгечә эш аты кебек эшләп йөри торган, үзен һәм гаиләсен тәэмин итеп тора торган, шуның сәбәпле иренә кул астындагы бер йомышчы итеп кенә карый торган хатын һәм хатыны эшләп тапканны ашап, киеп, шуңа күрә хатынының акырганына-кычкырганына риза булып, мескен хәлдә диванда кырын ятып телевизор карый торган ир түгел. Киресенчә, ир-ат эшләргә, гаиләне тиешенчә тәэмин итәргә тиеш. "Мин - ир, шуның өчен мин өстен булырга тиеш", - дип кенә өстенлеккә ирешеп булмый. Өстенлеккә зур тырышлык белән генә ирешеп була. Ир-атның урыны хатынның итәк астында түгел, ул җәмгыятьтә булырга тиеш. Ир җәгыятьтә тиешле урында булсын өчен, хатын-кыз ир хатыны буларак өйдә булырга, ягъни иренең өендә көтүче булырга, иренең җәмгыять өчен тырышып йөрүен тәэмин итәргә тиеш.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# Диннәр тарихын укыту үзенчәлекләре

**Халыкара, милләтара һәм диннәр арасында татулык кеше шәхесенә, аның үсеш дәрәҗәсенә, нинди караштарыуына, нинди сыйфатларга ия булуына, нинди кыйммәтләргә өстенлек бирүенә бәйле. Икенче төрле әйткәндә, кешеләрнең нинди тәрбия алуы, кайсы тирәлектә үсүе, нинди принципларга өстенлек бирүе дә бу проблеманы уңышлы хәл итүгә йогынты ясый. Башка факторлар белән беррәттән, милләтара һәм диннәр арасында татулык урнаштыруда мәктәп, укытучылар, әти-әниләр йогынтысы, укыту һәм тәрбия бирү юнәлешләре дә зур әһәмияткә ия.**

Мәктәпләрдә укытыла башлаган диннәр тарихы дәресләре дә шушы максатны күз алдында тотарга тиеш. Диннәр тарихын укыту эчтәлеген билгеле бер алым, ысул, чаралар тәшкил итә. Бу дәресләрне укыту эшен оештырганда, Җир йөзендә таралган диннәр, аларга карата төрле халыкларда һәм милләтләрдә формалашкан карашлар турында мәгълүмат бирү, төрле дин тотучылар арасында татулык һәм түземлелек тәрбияләү таләп ителә. Шулай ук мәктәпләрдә диннәр тарихы дәресләрен укытканда, соңгы елларда халыкның дингә омтылышын, әхлак нормаларын кайтаруда аңа ышаныч белдерүен, ата-аналарның, укучыларның дини йолаларны үтәүгә күбрәк тартылуын да искә алмый мөмкин түгел.

Дин әһелләре әзерләү белән дини уку йортлары шөгыльләнә. Ә мәктәп эшчәнлегендә диннең урынын билгеләү, аңа мөнәсәбәт формалаштыру, динне файдалану алымнарын билгеләү бурычы тора.

Без мәктәптә дингә кагылышлы эшләрне башкарганда, түбәндәге кагыйдәләрне истә тотып эш итәбез:

1. Дин кабул итү, аның кануннарын үтәүнең һәр шәхеснең вөждан ирегенә бәйле булуы.

2. Барлык мөмкинлекләрне һәм чыганакларны файдаланып, диннәр тарихын өйрәнү, аларга хас үзенчәлекләрне һәм аларның әһәмиятен күрсәтү.

3. Дин тотучыга комачауламау, ярдәм итү. (Дин тоту укучыга тискәре йогынты ясамаска тиеш.)

4. Дини гореф-гадәтләрне тәрбия эшендә куллану.

5. Толерантлылык, динара мөнәсәбәтләрдә ихтирамлылык, милләтләр бергәлеге таләпләренә тугры булып, фән гыйлемнәрен дини мәдәният алымнары белән бергә алып бару.

Дәресләрдә диннәр тарихын гына түгел, ә дини мәдәниятне дин, фән, моң, мәгърифәт белән тыгыз бәйләнештә алып барганда гына без әхлакый яктан камил балалар тәрбияли алабыз.

Дин һәм фәннең үзара бәйлелеге, шулай ук сүз, дәгъват, үгет-нәсихәт һәм бу мәсьәләне яхшы белүче, мәгърифәтле мөгаллим-укытучы - төрле афәтләргә каршы көрәшүче төп көч. Вөждан - әхлак эчтәлегеннән торган дин, акыл-әхлак эчтәлеген хасил иткән фән балаларга аңлатылса, алдыбызда хакыйкать ачылыр. Россиядә меңнәрчә дин әһеле, галиме бар. Ни кызганыч, дин әһелләренең күбесе - фәнне, галимнәрнең шактый өлеше динне белми.

Алда әйтелгәннәрне истә тотып, мин үз эшемне, иң беренче чиратта, бу өлкәдә булган белемнәремне барлаудан һәм яңаларын туплаудан башладым. Тарих укытучысы буларак, диннәрнең килеп чыгу һәм яшәү тарихы миңа яхшы таныш. Һәр диннең нигезен ныклап өйрәнү өчен мин диннәрнең төп Китапларын укуны максат итеп алдым.

Эшемнең алдагы этабында мин дәреслек материалын ныклап өйрәнеп, дәрес эшкәртмәләре һәм күрсәтмә материал булдырдым.

Диннәр тарихы дәресләрендә төрле дәрес формалары: лекция, диспут, экскурсия, интервью-дәрес (укучылар биш минут эчендә үзләрен кызыксындырган сораулар әзерли, укытучы сорауларга җаваплар бирә) һ.б. кулланам.

Укучыларның белемнәрен ачыклау һәм ныгыту өчен дә төрле эш формаларына мөрәҗәгать итәм. Тест, эссе, кроссвордлар чишү, рефератлар һәм чыгышлар, төрле темаларга презентация проектлары әзерләү, тәрбия сәгатьләрендә чыгышлар ясау - шуларның кайберләре.

Дәресләрем үстерелешле, проблемалы һәм гамәли характерда үтә.

Фәнне тагын да тирәнтен укыту, укучыларның фән белән кызыксынуларын арттыру өчен, күптөрле алымнар кулланырга тырышам. Шул нисбәттән, дини чыганаклар белән таныштырам, укучыларның тормыш тәҗрибәсен кулланам, мәктәптән тыш вакытларда дин әһелләре белән очрашулар, гыйбадәтханәләргә сәяхәтләр оештырам. Анда катнашу-катнашмау һәр укучының үз эше, ягъни бу - шәхеснең вөждан ирегендә.

Аллаһы Тәгалә, барлык милләтләргә, кабилә-ыруларга тигез караштa булып, дус яшәргә, бер-беребезне өйрәнергә, күршеләрнең яхшы гамәлләрен үзеңдә булдырырга кушкан. Без бик кечкенә планетада яшибез, барыбыз да - Адәм (гс) балалары. Бу җирдә нинди тереклек бар, барысы да - Аллаһы Тәгаләнең гаиләсе. Күлдә коенсаң, чишмәдән алып су эчсәң, аңа төкермисең бит. Димәк, дин аша әйләнә-тирәгә сакчыл караш тәрбияләнә.

Үзенең улын тәрбияләүчегә киңәш биргәндә Готбә бине Әбу Суфьян: "Минем улымны тәрбияләү синең үз-үзеңне тәрбияләү булсын. Чөнки алар бөтен нәрсәгә дә синең күзең белән карый. Син хуплаганны хуплый, син начар дип тапканны начар диләр", - дип әйткән. Бу дәресләрне укытканда, башка дәресләрдәге кебек үк, укытучының шәхси үрнәге дә зур роль уйный.

Әлеге дәресләр аша балалар сектантларны, тылсымчы-сихерчеләрне, багучыларны да танырга өйрәнә. Чөнки бүгенге көндә төрле-төрле секталар барлыгы мәгълүм һәм аларның бурычы бер генә: традицион булмаган ят диннәрдән файдаланып, яшьләрне җәмгыятьтән, ата-анадан аеру, хәтта илдә булган нәрсәләргә каршы кую. Әлеге секталар исламга да, православие диненә дә каршы чыга. Алар хезмәт итмәскә, ата-ананы тыңламаска куша. Мондый чит идеологиягә каршы көрәш илебездә төрле юнәлешләрдә алып барыла. Радио-телевидение, матбугат аша ят диннәргә каршы чыгышлар ясала.

Әхлакый тәрбияне һәр дәрестә, һәр тәрбия чарасында алып баруның әһәмиятен танып, бу өлкәдә гаиләнең дә тоткан урынын аерып күрсәтәсем килә. Һәр бала динле булып туа, ә ата-анасы аны я мөселман, я яһүд, я христиан динен тотучы итеп тәрбияли. Шуңа күрә гаиләләр белән дә даими эш алып бару зарур. Аларны дәресләргә чакырам, ата-аналар җыелышларында чыгышлар ясыйм, аларны кызыксындырган сорауларга җавап бирергә тырышам.

Алда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, диннәр тарихы дәресләре кешелек җәмгыятендәге әхлакый нигезләрнең әһәмиятле состав өлеше булган халыкара, милләтара татулык һәм төрле дин тотучылар арасында түземлелек, әхлаклылык кыйммәтләре тәрбияләүдә искиткеч зур әһәмияткә ия.

***Гөлзия СӘЛӘХЕТДИНОВА,***
***Мамадыш районы Көмеш Күл урта мәктәбенең тарих укытучысы***



# Ш.МӘРҖАНИ ОБРАЗЫ ӘДӘБИЯТТА ҺӘМ СӘНГАТЬТӘ

**Шиһабетдин Мәрҗани - XIX гасырда татарның рухи хәятендә тирән борылыш ясаган, уяну-яңарыш дәверенә - ренессанска юл ачкан титаник шәхес, фикер иясе, милли мәдәният күгендә, бөтен Ислам дөньясында балкып торган олы якты йолдыз. Бөек реформатор, энциклопедист галим, мәшһүр мәгърифәтче.**



Халкыбызның бөек акыл иясе, даны һәм горурлыгы булган бу мәшһүр затка багышлап төрле телләрдә йөзләгән фәнни хезмәтләр, матур әдәбият әсәрләре языла, диссертацияләр яклана, сәнгать төрләре (бюстлар, рәсемнәр) иҗат ителә.

Бөек шәхесләр үз халкының тормышына, рухи дөньясына, шул исәптән аның сәнгатенә, хәтта аның бер төре булган матур әдәбиятына да билгеле бер дәрәҗәдә уңай йогынты ясыйлар, алга таба ул халыкның, ул милләтнең горурлыгына әвереләләр. Ш.Мәрҗани - шундый шәхесләрнең берсе. Данлы шәхесләргә бай булган татар халкының рухи дөньясында бу могтәбәр зат үзенә аерым, үзенчәлекле урын били. Шушы уңайдан, Мәрҗани шәхесенең татар шигъриятендәге, аның бер жанры булган мәрсия жанрындагы әсәрләрдә ничек чагылуы мәсьәләләренә берникадәр тукталып үтик.

Мәрсия - вафат булган кешеләрне олылап, мактап искә алучы, аларга карата ярату, ихтирам итү, хөрмәтле тойгыларын чагылдыручы шигъри әсәр. Мәрсияләрдә үзеннән соң фән, әдәбият, мәгариф, мәдәният өлкәсендә данлы исем калдырган шәхесләргә дан җырлана. Беренче чиратта, мондый шәхеснең күркәм, соклангыч кешелек сыйфатлары тасвирлана, туган халкына күрсәткән изге гамәлләре, хезмәтләре югары бәяләнә.

Ш.Мәрҗани шәхесенә багышлап Акмулла, Гали Чокрый, Нәҗип Думави, Габдулла Тукай һ.б. язган әсәрләр шушы төр мәрсияләргә карый.

1889 елда Ш.Мәрҗани вафаты уңае белән татар әдәбиятында моңа кадәр язылган мәрсия жанрындагы әсәрләрнең тематик офыклары киңәя төшә: аңа багышланган мәрсияләр татар әдәбиятында яңа тип мәрсияләр - алгы планга мәгърифәтчелек идеаллары куелып язылган, оптимистик рухтагы мәрсияләр тууга сәбәпче була.

Билгеле булганча, Ш.Мәрҗанигә багышланган иң беренче мәрсияләрне Мифтахетдин Акмулла һәм Гали Чокрый яздылар. Акмулланың "Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе" әсәре, мәгълүм булганча, шагыйрь тарафыннан Мәрҗани шәхесен һәм аның гыйлем өлкәсендәге эшчәнлеген мактауга багышланган мәдхия итеп языла башлый. Шагыйрь аны тәмамлагач, Казанга барып, Мәрҗанинең үз кулына бирергә ниятли. Әмма 1889 елның маенда педагог вафат булгач, шагыйрь әсәренә традицион мәрсия рухында аерым бер бүлек өстәп, аның кульъязмасын Казанга юллый һәм бу әсәр 1892 елда аерым китап хәлендә дөнья күрә. Анда Мәрҗани шәхесе наданлык дөньясында балкыган кояш, якты яшен нуры, энҗе-мәрҗән белән урынлы рәвештә чагыштырыла, мәшһүр галимнең даны ерак илләргә таралуы хакында әйтелә. Ш.Мәрҗанигә багышланган 506 шигъри юлдан торган мәрсиядә данлы галимнең туган халкын гыйлемле итү өлкәсендә башкарган изге эш-гамәлләре, мәгърифәтчелек идеяләре киң тасвирлана, аның шәхесен зурлап "караңгы фонарь кабызган зат", "тимерказык" булуы хакында җылы фикерләр әйтелә.

Ш.Мәрҗанигә багышланган икенче әсәр - Г.Чокрый мәдхиясе. Матбугатта аның бары тик дүрт юллы ике генә строфасы дөнья күргән. Аны укыгач, ирексездән: "Бу ике строфа зур күләмле шигъри әсәрнең бер өзеге генә түгелме?" - дигән карашка киләсең. Эчтәлеге белән ул мәдхия (ода) жанрына бик якын. Формасы ягыннан да ул классик мөрәббагъ (дүртьюллык) рәвешендә иҗат ителгән, строфа саен "һадилар кем безем саздыр" ("безне дөрес юлга салучы") дигән юл даими кабатлана. Текстта Мәрҗанинең башкарган эш-гамәлләре турында әйтелә, галимнең "шөһрәт һәм бөек фикер иясе", "күп фәннәр, хикмәтләр укып", "төрле мәсьәләләр ачып, күп дәлилләрне белүче, безне дөрес юлга салучы" зат булуы турында бәян ителә. Бу әсәр дә оптимистик рухта язылуы белән сыйфатлана.

Уфадагы Зәки Вәлиди исемендәге Республика китапханәсенең өлкәне өйрәнү бүлегендәге Гали Чокрый фондында робагый белән 64 юллык күләмдәге мәрсиянең кульъязмасы саклана. Анда мәшһүр галимнең үлеменә тирән кайгы белдерелеп, фикер иясенең акылына дан җырлана.

XIX гасыр ахыры - XX гасыр башларында татар вакытлы матбугатында Мәрҗанинең вафатына 25 ел тулуны билгеләп үтүгә хәзерлек мәсьәләләре алга килеп баса. Бу чорда фикер иясенә багышлап шигырь язучылардан Н.Думави һәм Г.Тукай аеруча матур үрнәк күрсәттеләр. Н.Думави "Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләренең кабере янында" исемле шигырен шул уңай белән иҗат итә һәм ул "Йолдыз" газетасының 1912 елгы 24 июнь санында дөнья күрә. Оптимистик рухта иҗат ителгән бу әсәр, формасы ягыннан караганда, Акмулла мәдхиясеннән икеюллыклар ярдәмендә иҗат ителү белән генә аерыла. Әмма эчтәлек ягыннан шушы иҗат җимешләре аваздаш: аларда буеннан буена Ш.Мәрҗанинең халыкка гыйлем тарату өлкәсендәге эшчәнлеге, яхшы кешелек сыйфатлары, оптимизмы, батырлыгы тасвирлана, эш-гамәлләренең кыйммәте объектив рәвештә бәяләнә.

Г.Тукайның "Шиһаб хәзрәт" исемле шигъри әсәре дә бөек татар галименең туусына һиҗри ел исәбенә йөз ел тулу уңае белән иҗат ителгән кадерле мирасның бер кыйммәтле өлеше. Үзенең гомер сукмагы кыскаруны сизенгән шагыйрь, зур юбилей уңаеннан басылачак җыентыкны көтеп тора алмый, эчтәлеге, эчке рухы белән мәдхия жанрында нечкә зәвык белән язган шигырен "Аң" журналының 1913 елгы икенче санында бастыра. Тугыз строфаны тәшкил иткән бу поэтик әсәрнең түбәндәге соңгы тарихи юллары гына да мәшһүр галимгә шагыйрьнең мәхәббәте, ихтирамы нинди тирәнлектә булуын ачыклыйлардыр шәт:

Бер җан берлән тиздән милләт итә бәйрәм,
Шәрафәтләп туган көнне бу мөхтәрәм;
Җисме үлек, исме терек бу хәзрәтнең
Мәхшәргәчә телләр сөйләр, язар каләм.

Йөз еллыгы уңае белән Ш.Мәрҗанинең тарихи, мәгърифәти, мәдәни эшчәнлеген яктырту юлында "Аң" журналы 1913 елгы беренче һәм икенче саннарында изге гамәлләр башкара: анда Габдрахман Сөнгатинең "Мәрҗани хәзрәтләре" шигыре, Г.Ибраһимовның "Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре (юбилей мөнәсәбәте илә тәнкыйть)" дигән мәкаләсе урын ала. Г.Сөнгатинең шигыре:

Бәхетле син, даһи хәзрәт!
Көл Көрси өстендә,
Хәзер хак сүзләрең угрында
корбан барча җан инде,

- дигән җылы фикерләр белән тәмамлана; Г.Ибраһимов мәкаләсендә: "Таң алдыннан чулпан күренә, Чулпан белән бер вакытта Җир йөзе тагы ныграк караңгылана. Мәрҗани - безнең таңыбызның Чулпаныдыр", - дигән бәяләмә бирелә.

"Кояш" газетасының 1915 елгы 9 гыйнвар һәм 16 апрель саннарында Ф.Әмирханның Ш.Мәрҗани шәхесенә, гыйльми эшчәнлегенә олы ихтирам белән сугарылган "Безнең хыялларда Мәрҗани күләгәсе", "Мәрҗани хатирәсенә мәҗмуга" исемле мәкаләләре лаеклы урын алганнар. Сәйфи Кудашның: "Татар-башкорт халыкларының иҗтимагый фикер үсеше тарихында Мәрҗанинең хезмәтләре зур әһәмияткә ия булып торалар. Шунлыктан, татар-башкорт халыкларының иҗтимагый фикер үсешен яктыртканда, Мәрҗанине һич тә читләтеп үтәргә мөмкин түгел", дигән фикерләре ике тугандаш халыкның рухани үсешендә әһәмиятле роль уйныйлар.

"Мәрҗани" җыентыгында басылган Р.Фәхреддин, Й.Акчура, Х.Габәши, Г.Баруди, Б.Шәбкәви, Ә.Максуди, Буа Нургали хәзрәт, Г.Ибраһимов, Хәбибенназар хәзрәт, Һ.Атласи, М.Түнтәри, Ш.Морад, Буа Габдулла хәзрәт, Б.Шәрәф, Х.Кызылҗари, Ә.Вәлиди, Б.Мәрҗани һ.б. мәкаләләре дә татар зыялыларының бөек галимгә булган җылы мөнәсәбәтен чагылдыралар. Күренекле дин галиме һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог Шәһретдин Шәрәфетдин Шиһаб хәзрәтнең вафаты вакытында һәм вафатыннан соң өч дистәдән артык дин әһелләренең мәшһүр затка багышланган бик күп мәрсияләр, шигырьләр иҗат итүләре турында горурланып белешмә бирде.

**(Ахыры газетабызның киләсе санында.)**

***Фәнис ИСЛАМОВ,***
***педагогика фәннәре кандидаты***

2012 ЕЛ - ТАРИХИ-МӘДӘНИ МИРАС ЕЛЫ

# Кышкар авылы мәчете

**Кышкар авылы мәчетенең тарихы XVIII гасыр ахырына барып тоташа. Ул 1774 елда иң бай сәүдәгәрләрнең берсе - Баязит бине Госман әл-Кышкарый тарафыннан салынган. Әл-Кышкарый һәм аның варис оныклары мәгариф, мәгърифәтчелек файдасына иганәчелек белән шөгыльләнгәннәр. Шул ук вакытта алар мәчет каршында мәдрәсә дә төзетә һәм ул атаклы уку йортына әверелә. Биредә хәтта Казан, Оренбург, Касыйм, Семипалаттан килеп гыйлем алганнар. Мәдрәсәдә бөек Тукаебызның әтисе Мөхәммәтгариф хәзрәт, күренекле артисткабыз Галия Кайбицкаяның әтисе Мотыйгулла хәзрәт, әдәбият тарихында билгеле шәхес Таип Яхин кебек кешеләр укып чыккан.**

2002 елның 13 сентябрендә 225 еллык тарихы булган бу бина зур тырышлыклар белән төзекләндерелеп, яңадан мәчет итеп ачыла. Шушы көннән башлап мәчетебез сукмагыннан авыл халкының, без - укучы балаларның өзелгәне юк. Беренче көннән Мәсхүт хәзрәт балаларга дин гыйлемен өйрәтә башлый. Авыл картларын җомга намазына китерү өчен зур тырышлык куя. Мәсхүт хәзрәтебез вафат инде, урыны җәннәттә булсын.

Бүгенге көндә бу изге эшне мәчетебезнең имам-хатыйбы Радик хәзрәт һәм авылыбызның абыстае - Илсөя остазбикә дәвам итә. Радик хәзрәт 1999 елда хаҗ кылып кайтканнан соң, Казандагы Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә белем алган.

Мин мәчет каршында оештырылган якшәмбе укуларына дини гыйлем алырга йөрим. Безгә дини гыйлемне мөгаллимәбез Разидә апа бирә. Дәресләрдә гарәп хәрефләрен танырга, намаз укырга өйрәнәбез.

Мәчеттә дини гыйлем алу белән беррәттән, дини бәйрәмнәр, ифтар мәҗлесләре уздыру гадәткә кереп бара. Күренекле дин әһелләре белән очрашулар уздырыла, "Ак калфак" татар хатын-кызлары, "Мөслимәләр", "Дәү әниләр" оешмасы әгъзасы булып торган Сәйдә абыстай белән очрашу без - шәкертләр һәм авыл халкына зур бүләк булды. Сәйдә абыстайның вәгазьне тормыш белән бәйләп сөйләве үзе бер тәрбия чарасы иде. Габделхак хәзрәт Каюмовтан беренчеләрдән булып дини гыйлем алган, Арча халкына шәригать хөкемнәрен аңлатучыларның берсе булган Наҗия абыстай кунагыбыз иде. Бу очрашуда мөгаллимәбез Разидә апаның остазы - Арча мөхтәсибәтенең өлкән абыстае Хөсния остазбикәнең дин тотуның асылына төшендерүе, тәрбияви вәгазь бирүе күңелләребезне тагын да сафландырды.

Кышкар халкы үз асылына кайта, әлхәмдүлилләһ. Җомга намазларына йөрүче олылар саны баштарак 9-10 булса, аларның сафларын яшьләр тулыландыра. Бүгенге көндә җомга намазына 30-35 кешенең йөрүенә имам-хатыйбыбыз Радик хәзрәтнең тырышлыгы белән ирешәбез. Ул һәр йортка кереп аңлату эшләре алып бара, дини тәрбиянең гаиләдә башланганлыгын төшендерергә тырыша. Җомга вәгазьләрен һәрдаим аңлаешлы, тәрбияви, тормыш белән бәйләнешле дәлилләр китереп сөйли. Шуңа күрә җомга көнне вәгазь тыңлаучылар саны арта бара, ә җәй көнендә укучы балалар да җомга намазларына бик теләп йөри. Шулай итеп, җомга көннәрне мәчеттә олы бер бәйрәм рухы сизелә. Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән, Рамазан аенда тәравих намазлары уку, ифтар мәҗлесләре уздыру, корбан чалуны авыл халкы изге гамәл буларак кабул итә, фарыз, ваҗиб гамәл икәнлеген аңлый.

Өч ел рәттән шәһәр балалары да җәй көннәрендә мәчеттә дини гыйлем алалар. Хәзрәтебез бик ягымлы. Чәй өстәле әзерләп, балаларны тәмле ризыклар белен сыйлый, әдәп-әхлак дәресләре үткәрә. Әти-әниләр дә, әби-бабайлар да рәхмәтле аңа.

Авылыбызның киләчәге өметле. Без бик тә шат.

**Рузилә ТӨХВӘТУЛЛИНА,**
**Арча районы Кышкар авылы**

# КҮП ХАТЫНЛЫЛЫК

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

Җәмгыятьтә бүгенге көндәге кебек демографик процесслар, наркомания, зина, җинаятьчелек кебек төрле тискәре күренешләр булмасын өчен ул күп итеп бала табарга һәм тапкан балаларына дөрес тәрбия бирергә тиеш. Шул чагында гына җәмгыять алга барырга мөмкин.

Пәйгамбәребез (сгв) әйтә: "Әгәр бер милләтнең башына хатын-кыз куелса, ул милләтнең кыямәте җиткәнен көт тә тор", ди. Хатын кулына калган, хатын сүзе белән йөри торган милләтебез бүген үзенең кыямәтенә якынлаша. Дөнья ул шундый нәрсә: я ул синең колың була, я син аның колы буласың. Әгәр син аны бик нык ярата башлыйсың икән, син аның колына әвереләсең, һәм әгәр син аны яратмыйсың һәм аңа игътибар итмисең икән, ул синең колыңа әверелә. Беренче мөселманнарның дөньяга, дөнья малына мәхәббәтләре булмавы аларны шул дөньяга хуҗа итеп куйды һәм алар бик кыска вакыт эчендә нинди куәтле дәүләтләрне, халыкларны буйсындырып Җир өстендә Ислам динен урнаштырдылар. Ә, хаклыкта, дөнья фәкать Адәм баласына кулланыр өчен һәм ләззәтләнер өчен генә бирелгән. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Белегез! Бу дөнья тереклеге, хаклыкта, уен һәм көлке, зиннәтләнү һәм арагыз да үзара масаеп мактану, һәм маллар белән балалар арттыруда ярышу гына" (57:20).

Пәйгамбәребез (сгв) хатын-кызны ләззәт, ди. Хатын-кызлар да, күбесенчә, ирләрдән үзләренә күбрәк игътибар бирүләрен, иркәләүләрен, наз һәм алар белән ләззәтләнүне таләп итәләр. Аерылучы гаиләләрдәге ир хатыныннан "Нигә аерыласыз?" дип сорагач: "Ничә ел бергә торабыз, аның мине бер кочаклаганы, иркәләгәне, назлаганы да юк", - дип җавап бирүчеләр дә аз түгел. Бүгенге ирләрнең күбесенә мөлаем, көләч, иркәләнә торган түгел, ә эш аты булган, акча эшли торган һәм өйдәге бөтен эшләрне башкара торган хатын кирәк. Бу проблема, бәлкем, мөселман ирләргә күбрәк та кагыла торгандыр. Аллаһы Тәгалә аларның теләкләрен кабул итә, ул ирләр акча да таба торган һәм өендә дә бөтен эшләрне башкара торган хатынга өйләнәләр. Әмма күңелләре, нәфселәре урамдагы уенчак хатыннарда кала. Андый ирләр зина кылуга сәбәп эзли башлыйлар. Шул вакыт ислам динендәге күпхатынлылыкның рөхсәт ителүе аларның проблемаларын хәл итәр кебек тоела башлый. Ир буларак беренче хатыны өстендәге бурычларын үтәмәгән, торырга йорты да булмаган көенчә икенче хатын турында хыяллана башлыйлар. Ә бит хатыннарның ризалыгыннан башка аларны бер йортта тоту тыела. Чөнки аерым йорт таләп итү аларның хакы. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә кисәтә: "Никахлану өчен мал таба алмаган ярлы кешеләр Аллаһ аларга байлык биргәнгә чаклы сабыр итсеннәр һәм зинадан саклансыннар" (24:33).

Сүз дә юк, Аллаһы Тәгалә күп хатынлылыкны рөхсәт иткән. Моны беркемнең дә инкарь итәргә хакы юк. Бу хакта Коръәндә һәм хәдисләрдә әйтелә, сәхәбәләр тормышында күренә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салл-Аллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхәбәләреннән булган Сәгыйд бин Җүбәйрдән риваять кылына: "Ибне Габбас миннән сорады: "Син өйләндеңме?" Мин әйттем: "Юк". Шуннан соң ул миңа әйтте: "Өйлән! Хакыйкатьтә, бу өммәтнең иң хәерле кешесе - күп хатынлысы" (Бохари, 4681).

Ислам динен яхшы белүче олуг сәхәбәләрнең берсе булган ибне Габбас күп хатынлы булган кешене "өммәтнең иң хәерле кешесе" дип атый. Чынлап та, күпләр күп хатынлылыкның төп мәгънәсен аңламыйлар. Чынлыкта, ул бүгенге көндә милләтне саклап кала торган төп факторларның берсе булып тора. Бер хатын белән торган ир-атның бөтен эше шушы хатын белән шөгыльләнүгә әйләнә, ул аңардан пот ясый, аңа табына башлый, ә күп хатыны булган ир, күп пот ясый алмый һәм ул аларга табына да алмый, ул күп хатынны тәрбияләргә мәҗбүр була. Димәк, ялгыз хатыннар бетә, җәмгыятьтә ир-атлар һәм хатын-кызлар мәсьәләсендә тигезлек барлыкка килә, нәтиҗәдә зина бетә, эчкечелек бетә, ир-ат үз урынын ала, ул инде берьюлы ике, өч, яисә дүрт хатынның итәкләре астында ята алмый, ул гаиләләре өчен, җәмгыять өчен тырышырга мәҗбүр була, җәмгыятьтә тәртип урнаша, халык та кимүдән туктаячак. Милләткә авыр чорлар килгәндә күпхатынлылыкка мөселман булмаган халыклар да игътибар иткәннәр, үзләренең дини тәгълиматләренә каршы килеп булса да, ил күләмендә күп хатынлылыкны хуплаганнар.

Мәсәлән, Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Германиядә хатын-кызлар ирләрдән 7,3 миллионга күбрәк булалар. Хатын-кызлар үзләренең тәннәрен сатып түгел, хәтта, киресенчә, үзләре үк шоколад, сигарет һәм икмәк биреп солдатлар белән якын мөнәсәбәтләргә кергәннәр. Хатын-кызлар белән ирләр арасындагы сан аермасы 1948 елда Мюнхен шәһәрендә уздырылган халыкара яшьләр конференциясендә тикшерелә. Бу мәсьәлә җентекләп тикшерелгәннән соң, очрашуда катнашучылар бу ситуациядән чыгуның бердәнбер юлы күпхатынлылыкта икәнлеге белән килешәләр һәм конференция ахырында күпхатынлылык резолюциягә кертелә. Ә бит немецлар мөселманнар түгел!

Мондый мисалларны бик күп китерергә булыр иде. Әмма эш мисал китерүдә һәм халыкларның күп хатынлылыкка булган мөнәсәбәтендә генә түгел. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Әгәр хатыннарның ятимнәрен никахланган сурәттә гаделсезлектән курыксагыз, ятим булган кызлардан күңелегезгә хуш килгән икешәр, өчәр, дүртәр хатынны никахлап алыгыз" (4:3).

Бу аять бер иргә дүрт хатынга кадәр алуның дөреслегенә дәлил булып тора. Алда Аллаһының сүзен инкарь итүнең нинди нәтиҗәләргә китергәнен карап киттек, мөмкин кадәр аңлатырга тырышып карадык. Акылы бар кешегә аңларлык. Әмма күпхатынлылыкның төп мәгънәсе - бер Аллаһка гына мәгълүм һәм Аллаһның сүзе һәрнәрсәдән дә өстенрәк.

Шул ук вакытта аңларга кирәк: беркем дә беркемне дә мәҗбүр итә алмый. Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: "Әгәр хатыннар арасында гаделсезлек кылудан курыксагыз, бер генә хатын белән никахланыгыз" (4:3).

Совет чорында, динсезлектә формалашкан фикер дини кануннарны кабул итә алмый. Әлбәттә, күпхатынлылык күп проблемалар тудыра. Пәйгамбәребез (сгв) хатыннары да, сәхәбәләрнең хатыннары да бер-берсеннән көнләшкәннәр, әмма үзләренең көнчелекләрен тыя алганнар, чиктән узмаганнар. Мөселман кешесе күп хатын алырга уйласа, беренче чиратта, чибәр, яшь кызлар турында түгел, бәлки ятим хатыннар, ятим балалар турында уйларга тиеш. Аның күңелендә өстенлек нәфесне канәгатьләндерүгә түгел, бәлки ятим хатыннарны, ятим балаларны тәрбияләүгә бирелергә тиеш. Күп хатын алганда, баймы-ярлымы, яшьме-картмы, чибәрме-чибәр түгелме, нинди генә хатын алуына карамастан, һәр хатынга да тигез караш, тигез мөнәсәбәт булырга тиеш. Әгәр дә моның үтәлүеннән куркасың икән, алда әйтеп кителгән аятьтәгечә, бер генә хатын белән никахлашырга һәм шуңа канәгать булырга кирәк.

Ислам дине күпхатынлылыктан башланмый һәм Ислам диненең төп мәгънәсен күп хатынлылыкка гына кайтарып калдырырга кирәкми. 25-30 ел бергә торып, кисәк кенә икенче хатын алырга уйлаган ирне хак дип, аның икенче хатын алуына каршы булган хатынын гына гаепләү дөреслеккә туры килми. Ир-ат акыл белән эш йөртсә, хатын-кыз күңел белән, эмоция белән эш йөртә. Ничә дистә еллар динсезлектә тәрбияләнгән, кечкенәдән күп хатын белән куркытып үстерелгән, мин аның бердәнбере булам дип кияүгә чыккан, ничә еллар бердәнбере булып яшәгән, балалар тапкан, аларны тәрбияләгән, үстергән хатыннар бүгенге көндә иренең икенче хатын алуына караганда зина кылуын җиңелрәк кичерә. Бу очракта ир-атны да акыл белән эш йөртә дип әйтеп булмый. Гомумән, тормышта кеше акылы белән аңлатып булмый торган нәрсәләр бик күп. Шуңа күрә дә күп нәрсәне Коръәнгә, пәйгамбәребез (сгв) сөннәтләренә кайтарырга, күп нәрсәдә пәйгамбәребез (сгв) яшәү рәвешеннән үрнәк алырга кирәк. Пәйгамбәребез (сгв) үзеннән 15 яшькә зур булган Хәдичә (рг) белән никахлашып, 28 ел бергә гомер кичерә һәм ул исән вакытта икенче хатын турында уйлап та карамый.

Күпхатынлылык катлаулы мәсьәлә. Ул иргә, хатынга охшау-охшамауга карамый. Бүген күп кенә милләтчеләр "Милләт бетә" дип лаф оралар. Шулай булуга карамастан, күпхатынлылык проблемасына салкын карыйлар, яисә, гомумән, кире кагалар. Ә бит күпхатынлылык дин проблемасы булуга караганда, күбрәк милләт проблемасы. Чөнки ислам дине - Аллаһы Тәгаләнең дине. Ул бер хатын белән, яисә күп хатын белән торуга, халыкның күплегенә-азлыгына, яисә милләтләрнең ниндилегенә бәйле түгел. Бүгенге көндә диннең күтәрелүе бөтен кешегә дә күренә. Аллаһы Тәгалә халыкларны фәкать Ислам диненә яраклы гына итеп яраткан. Милләтен, халкын яраткан кеше бу хаклыкны аңларга, бу хаклыкка иярергә һәм бу хаклыкка буйсынырга тиеш. Телдән үзен мөселман дип, гамәлдә ислам динендә әйтелгәннәр белән килешмәгән кешене мөселман дип әйтеп булмый.

Аллаһы Тәгалә һәммәләребезне дә Үзен генә танучы, Үзенә генә табынучы һәм Үзенә генә буйсынучы, гыйбадәт кылучы сөекле колларыннан насыйп кылса иде.



**Рөстәм хәзрәт ШӘЙХЕВӘЛИЕВ,**
**ТР мөселманнары Диния нәзарәте Президиумы әгъзасы,**
**Кама буе төбәге казые,**
***Чаллы шәһәрендәге Ак мәчет имамы***

# Кешеләргә дин кирәк

**(Ахыры. башы 1 нче биттә.)**

Гасырлар дәвамында ислам, христиан һәм иудаизм диннәрендә булган тыюларга карата шик-шөбһәләр юк иде. Аллаһы Тәгаләгә инанган кеше бар нәрсәнең дә - яхшының да, начарның да Аллаһы Тәгаләдән булуын белә. Җирдәге тормышның алдагы мәңгелек тормыш алдында кечкенә генә тукталыш булуын аңлый.

Тормышының киләчәге аның үзенә бәйле булуын аңлаган кеше рухи яңарышка таба беренче адымнарны ясарга үзендә көч табарга тиеш. Бер тапкыр иман түбән татып караган һәм аның көченә ышанган кеше туры юлдан беркайчан да тайпылмаячак.

***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***


## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ШИМБӘ | 31.03.12 | 4:46 | 6:16 | 13:02 | 17:14 | 19:20 | 20:50 |
| ЯКШӘМБЕ | 1.04.12 | 4:44 | 6:14 | 13:02 | 17:15 | 19:22 | 20:52 |
| ДҮШӘМБЕ | 2.04.12 | 4:41 | 6:11 | 13:02 | 17:17 | 19:24 | 20:54 |
| СИШӘМБЕ | 3.04.12 | 4:38 | 6:08 | 13:02 | 17:18 | 19:26 | 20:56 |
| ЧӘРШӘМБЕ | 4.04.12 | 4:36 | 6:06 | 13:02 | 17:19 | 19:28 | 20:58 |
| ПӘНҖЕШӘМБЕ | 5.04.12 | 4:33 | 6:03 | 13:02 | 17:21 | 19:31 | 21:01 |
| ҖОМГА | 6.04.12 | 4:31 | 6:01 | 13:02 | 17:23 | 19:33 | 21:03 |
| ШИМБӘ | 7.04.12 | 4:28 | 5:58 | 13:02 | 17:24 | 19:35 | 21:05 |

# Онытмам

ЯҢА КИТАП

***«Иман» нәшрияты яшь авторның тәүге китабын бастырып чыгарды. Китапка А.Шәйхинең төрле жанрларда иҗат ителгән әсәрләре кертелгән. Китап «Таян Аллага» китапханәсе сериясендә дөнья күргән. Автор белән танышу өчен, сезнең игътибарыгызга аның автобиографиясеннән өзек тәкъдим итәбез: «Мин – Айдар Шәйхи. Әлбәттә, бу минем тәхәллүсем. Тулы атым – Айдар Рәсим улы Шәйхин. Мин Актаныш районы Әтәс авылында 1997 елның 6 сентябрендә дөньяга килгәнмен.***




2004 елда беренче мәртәбә мәктәп ишекләрен ачып кердем. Тырышып укыйм, әлхәмдүлилләһ! Шактый гына уңышларга да ирешергә насыйп булды. Шуңа күрә, 2011 елдан мин Актаныште сәләтле балалар өчен ачылган гуманитар гимназия-интернатта белем алам.

Кайчандыр, бер гүзәл мизгелдә, мин кулыма каләм алдым һәм язарга тотындым. Шулчак каурый каләм мине сихерләде, үзенә буйсындырды... Гаҗәеп фикерләр килә башка, аларны кешелеккә хәбәр итәргә телим. Шул теләк мине тагын, тагын язарга этәрә...

Язган әсәрләрем белән төрле бәйгеләрдә катнашырга насыйп булды. Мәсәлән, II «Таян Аллага» әдәби бәйгесенең «Чәчмә әсәрләр» номинациясендә III урынга лаек булдым. «Inter@каләм» шигырь бәйгесендә үзенчәлекле шигырь буенча җиңдем. Уку, фән һәм иҗат бергә үрелеп барганга күрә, мин күптөрле фәнни-гамәли конференцияләрдә чыгыш ясыйм. Әйтергә кирәк, күбесендә җиңүгә ирештем. Фән олимпиадаларында да күптәннән катнашып, югары урыннар алып киләм.

Бүгенгесе көндә мин гуманитар гимназия газетасының баш мөхәррире, «Ялкын» яшүсмерләр журналында редколлегия әгъзасы, «Сабантуй» газетасының яшь хәбәрчесе. Иҗат юлына кереп барам бугай инде. Аллаһ боерса, әдәби эшчәнлегемне киләчәктә тарихыбыз белән бәйләргә телим. Бары да Хак Тәгалә кушканча булыр, әлбәттә. Тик минем асыл максатым – Раббыбызның бездән ни таләп иткәнен аңлап һәм аның таләпләрен үтәп, өммәтебезгә, милләтебезгә хезмәт итәргә. Иншә Аллаһ, без булдырырбыз!»

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №13 (130) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма − Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-529.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 29 март көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы − "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакла免ыгыз!**